РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
БЮРГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БОЕРГАН
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

15 июль 2021 ел № 1-24

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Боерган авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект карары хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, Россия Федерациясе Граждан кодексы, «СанПиН 2.1.7.3550-19 санитар-эпидемиологик кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында «Муниципаль берәмлекләр территорияләрен тотуга санитар-эпидемиологик таләпләр һәм нормалар раслау турында» Россия Федерациясенең 2019 елның 05 декабрендәге 20 номерлы баш дәүләт санитария табибының карары нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Боерган авыл җирлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Боерган авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Боерган авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Боерган авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 14 ноябрендәге 44-1 номерлы карары белән расланган (14.07.2018 № 55-3, от 10.09.2019 № 74-1, от 05.08.2020 № 92-1, от 25.12.2020 № 3-7 карарлары редакциясендә), Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Боерган авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә (алга таба - Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

93 пунктны үзгәртергә һәм киләсе редакциядә бәян итәргә:

«93. Стационар булмаган объектларны урнаштыру мондый объектларны муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә урнаштыру схемасы буенча, хокук иясенең стационар булмаган объектка хокук билгели торган документлары булганда гамәлгә ашырыла.

Тиешле тәртиптә оешкан һәм дәүләт кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләре милекчеләре өчен, әгәр бу Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри таләпләрне бозмаса, аларда стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында карар кабул итү мөмкинлеге кире кагылмый..»;

156.13 пунктын төшереп калдырырга;

156.14.-156.17 пунктлар нумераиясен 156.13.-156.16. нумераиясе дип санарга

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Буа муниципаль районы Боерган
авыл җирлеге башлыгы И.В. Малышева